| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.10.2023 Менделеевск ш. №647

Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты,

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. 2023 елның 1 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Менделеевск шәһәре, Фомин ур., 19 йорт адресы буенча Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында, актлар залында кадастр номеры 16: 27:110144:382 булган Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Менделеевск шәһәре адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү бирү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга, (җир кишәрлегеннән файдалануның рөхсәт ителгән төрен «Территорияне төзекләндерү» дән «Кибет»кә үзгәртү).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

Готин Ю.А. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте архитекторы;

Антоновская Н.И. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3. 2023 елның 01 ноябреннән 2023 елның 01 декабренә кадәр Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте бүлегендә җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча материаллар экспозициясен түбәндәге адрес буенча оештырырга: Менделеевск ш., Фомин ур., 19 йорт (5 кат).

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423650, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт (Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестицион һәм инфраструктур үсеш идарәсе» муниципаль автономияле учреждениесенең баш архитекторы исеменә).

5. Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендә рәсми сайтында https://Mendeleevsk.tatar.ru/ урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

башкаручы. Хәбиров Р.З.
8(85549)2-01-99